**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422635 РТ, Лаишевский район,
с.Атабаево, ул.Молодежная, д.1
Тел, факс: 8(84378)4-87-41

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
422635 РТ, Лаеш муниципаль районы,
Атабай авылы, Яшьлэр урамы, 1нче йорт
Тел, факс 8(84378)4-87-41

**№158** **2019 елның 7 октябреннән**

**"Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советы карары проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар һәм «муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 21.07.2005 ел, №97-ФЗ Федераль законнар, Татарстан Республикасының 28.07.2004 ел, №45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законы нигезендә Атабай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Камская новь» («Кама ягы») район газетасында, махсус мәгълүмат стендларында һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә): http://pravo.tatarstan.ru.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Атабай авыл җирлеге Советы рәисе Л.Р. Хәлиловка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Атабай авыл җирлеге**
**Башлыгы, Совет рәисе** **Л.Р.Халилова**

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Атабай авыл җирлеге**
**Советының 2019 елның 7 октябрендәге**
**158 номерлы карарына Кушымта**

## “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр”

*23 статьяның 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «9. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыграгы катнашуда вәкаләтле, әлеге Устав нигезендә гражданнар җыены Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Атабай авылында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый.»*